**ГЛАВА КУРКАЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422730, Республика Татарстан, Высокогорский район,
пос.ж.д.рзд. Куркачи, ул.Гагарина, 7

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОРКАЧЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Коркачык тимер юл разъезды поселогы, Гагарин ур, 7

Тел./факс: +7(84365) 71-2-15, e-mail: Kurk.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**24 октябрь 2024 ел** **№ 17**

**Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлегенең Коркачык тимер юл разъезды поселогында гражданнарның үзара салым акчаларыннан кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге муниципаль берәмлек башлыгы »

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге  Коркачык тимер юл разъезды бистәсендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 07.11.2024 16 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге  Коркачык тимер юл разъезды бистәсендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 07.11.2024 18 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын уздыру өчен Коркачык тимер юл разъезды бистәсендә яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүлергә:

1 этап: Заречная ур., Королев ур., Сәйдәш ур., Лесная ур., Тукай ур., Строителей ур., Гагарин ур.

2 этап: Горький ур., Мирная ур., Заводская ур., Молодежная ур., Трудовая ур., Набережная ур., Энергетиков ур.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2025 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге  Коркачык тимер юл разъезды бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, свода катнашучы халыктан, аларның бергә яшәүче гаилә әгъзаларыннан, 1 төркем инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәреннән тыш һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы сез?

- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау;

- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

- торак пункт территориясен төзекләндерү;

- халыкның күпләп ял итү урыннарын (паркларны, скверларны, яр буйларын, пляжларны, спорт мәйданчыкларын һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

-  торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.

« ӘЙЕ»　　　　　　　　　　«ЮК».

5. Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча әлеге карарны халыкка җиткерергә: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　　　Р.Ф. Салихҗанов